**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 18 июненнән № 10-68

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 26 июнендәге 39-219 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Җирле үзидарәне бердәм публик хакимият системасында оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2018 елның 26 июнендәге 39-219 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2025 елның 20 ноябрендәге 3-19 номерлы карары белән үзгәртелгән редакциядә;) расланган Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.1. пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның, һәм муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында муниципаль норматив хокукый актта каралган дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр бирү хакында;»;

1.2. Нигезләмәнең 3.7. пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның, һәм муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында федераль канунчылык таләпләре буенча бирелгән белешмәләр дөрес һәм тулы икәнен билгеләргә;»

б) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның, һәм муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында норматив хокукый акт буенча бирелгән белешмәләр дөрес булмавын һәм (яки) тулы булмавын билгеләргә.

Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга киңәш итә.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А.Тарнавский